РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

14.01.2019 Олы Кайбыч авылы № 01

**Вазыйфаи инструкциягә үзгәрешләр кертү турында**

2007 нче елның 2 нче мартында чыккан 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законы, 2008 нче елның 25нче декабрендә чыккан 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законы, терроризмга каршы Милли комитетның 2018 нче елның 10 апрель утырышы протоколы, 2013 нче елның 25 нче июнендә чыккан 50-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы муниципаль хезмәт турында Кодексы» нигезендә, район Башлыгының коррупциягә каршы ярдәмчесе, АТК сәркатибенең вазыйфаи инструкциясенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә «Район Башлыгы ярдәмчесе вазифасы кандидатының белем һәм күнекмә дәрәҗәсе һәм характерына, белеменә, муниципаль хезмәт стажы яки белгечлеге буенча эш стажына (тәҗрибәсенә) квалификацион таләпләр» 2.2, 2.3 статьяларны түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр белән тулыландырырга:

« 2.2.Экстремизм һәм терроризмга каршы һәм профилактика өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне көйләгәндә,түбәндәге норматив хокукый актларны белергә кирәк:

- 1997елның 17 декабрендә чыккан 2-ФКЗ номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәте турында» Федераль конституцион законын;
- Россия Федерациясе җинаять кодексын;
- Россия Федерациясе административ хокук бозулар Кодексын;
- 2006 нчы елның 6мартында чыккан 35-ФЗ номерлы «Терроризмга каршы тору турында» Федераль законын;
- 2007 нче елның 9 февралендә чыккан 16-ФЗномерлы «Транспорт куркынычсызлыгы турында» Федераль законын;
- 2010нчы елның 28 нче декабрендә чыккан 390-ФЗномерлы «Куркыныч-сызлык турында» Федераль законын;
- 2011нче елның 21 нче июлендә чыккан 256-ФЗ номерлы «Ягулык-энергетика комплексы объектларының иминлеге турында» Федераль законын;
- 2009нчы елның 5 октябрендә Россия Федерациясе Президенты раслаган Россия Федерациясендә терроризмга каршы тору Концепциясе ;
- Россия Федерациясе Президентының 2006нчы елның 15 февралендә чыккан 116номерлы «Терроризмга каршы тору чаралары турында» Указы;

- Россия Федерациясе Президентының 2012нче елның 14 июнендә чыккан 851номерлы «Шәхес, җәмгыять һәм дәүләт куркынычсызлыгын булдыру буенча террорчылык куркынычы дәрәҗәсен билгеләүдә өстәмә чаралар күрү тәртибе турында » Указы;

- Россия Федерациясе Президентының 2015нче елның 26 декабрендә чыккан 664 номерлы «Терроризмга каршы тору өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү чаралары турында» Указы;

- Россия Федерациясе Президентының 2015нче елның 31 декабрендә чыккан 683номерлы «Россия Федерациясендә милли куркынычсызлык Стратегиясе турында» Указы;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004нче елның 1 июнендә чыккан 260нчы номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Регламенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте Аппараты турында Нигезләмәсе турында» Карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 нче елның 19 гыйнварында чыккан 30нчы номерлы «Башкарма властьның федераль органнары мөнәсәбәте Типик регламенты турында» Карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 нче елның 4 маенда чыккан 333нче номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәте җитәкчелегендә гамәлгә куела торган Башкарма властьның федераль органнарының терроризмга каршы тору өлкәсендәндәге эшчәнлеге компетенциясе" Карары;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013нче елның 25 декабрендә чыккан 1244номерлы «Объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланганлыгы турында » Карары.

- Халыкара –хокукый актлар:

- Халыкара яклауга ия затларга, шул исәптән дипломатик агентларга каршы җинаятьләрне булдырмау Конвенциясе (НьюЙорк, 1973нче ел, 14 декабрь);

-Тоткыр басып алу белән көрәш турында Халыкара конвенциясе захватом заложников (НьюЙорк, 1973нче ел, 17 декабрь);

- 2006нчы елның 8 сентябрендә чыккан 60/288 номерлы «Берләшкән Милләтләр Оешмасының глобаль контртеррористик стратегиясе» БМО Генераль Ассамблеясы Резолюциясе;

- Шанхай оешмасының терроризмга каршы Конвенциясе (Екатеринбург, 2009нчы ел, 16 июнь).

2.3.Терроризмга һәм экстремизмга каршы тору һәм профилактика өлкәсендә мөнәсәбәтләрне көйләүдә башка һөнәри белемнәр:

- «Терроризмга каршы тору гомумдәүләт системасы» төшенчәсе;

- Милли антитеррористик комитетның башкарма властьның федераль органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма власть органнары һәм җирле үзидарә органнарының терроризмга каршы торуны оештыру һәм координацияләү эшчәнлеге;

- Терроризмга каршы тору өлкәсендәге эшчәнлеген Россия Федерациясе Хөкүмәте гамәлгә куя торган башкарма власть федераль органнарының төп компетенцияләре;

- башкарма власть федераль органнарының терроризмга каршы чараларны үтәүне оештыру тәртибе;

- объектларны (территорияләрне) антитеррористик саклауга таләпләр;
- террористик куркыныч дәрәҗәсен билгеләү тәртибе;
- террористик куркыныч дәрәҗәсен билгеләгәндә терроризмга каршы тору субъектлары куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча өстәмә чаралар эчтәлеге;
- террористик күренешләрне кисәтү һәм булдырмау максатында кулланыла торган дәүләт мәҗбүр итү чаралары;
- федераль дәүләт хезмәткәрләренең терроризмга каршы тору өлкәсендә вазыйфаларын үтәмәве яки тиешенчә үтәмәве өчен җаваплылык;
- Башкарма властьның федераль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнарының, физик һәм юридик затларның террористик акт куркынычы турында мәгълүматны тикшергәндә, шулай ук терроризмга каршы субъектларга террористик акт куркынычы турында хәбәр иткәндә мөнәсәбәте тәртибе;
- Башкарма властьның федераль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт власте органнары һәм җирле үзидарә органнарының терроризмга каршы тору өлкәсендә эшчәнлеген оештыру».

**А.И. Рәхмәтуллин**